**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.11.2015 № 831

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2015 елның 4 декабрендә теркәлде, № 3030

Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә
социаль хезмәтләрне күрсәтүчеләрнең социаль
хезмәтләрне күрсәтүе тәртибе турында
мәгълүмат бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентын
раслау турында

“Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль законны үтәү йөзеннән **боерык бирәм**:

1. Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләрне күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтүе тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымта итеп бирелүче административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) аппаратының бүлек җитәкчеләренә, Министрлыкның Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы һәм шәһәр округларындагы социаль яклау идарәләре (бүлекләре) начальникларына һәм Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмалары җитәкчеләренә: Регламент нигезләмәләрен тайпылышсыз үтәүне тәэмин итәргә.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Ю.И. Әбдриевага йөкләргә.

**Министр** **Э.Ә.Зарипова**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 12.11.2015 ел, № 831 боерыгы белән расланды

**Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләрне күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтүе тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләрне күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтүе тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең бу административ регламенты (алга таба – Регламент) гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләрне күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтүе тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә гариза бирүчеләр булып, Россия Федерациясе гражданнары, Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар, шулай ук оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тора.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү Татарстан Республикасының муниципаль районнарындагы (шәһәр округларындагы) Социаль яклау идарәләре (бүлекләре) (алга таба – территориаль органнар) йөзендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасының дәүләт йөкләмәсе (заказы) урнаштырыла торган социаль хезмәт күрсәтү оешмалары (алга таба – социаль хезмәт күрсәтүче оешмалар) тарафыннан тормышка ашырыла.

1.3.1. Территориаль органнарның, дәүләт хезмәте күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының урнашу урыны, белешмәләр алу өчен телефоннары, электрон почта адреслары турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru) "Территориаль органнар һәм аларга буйсынучы учреждениеләр" бүлегендә, шулай ук бу Регламентка белешмә-кушымтада күрсәтелгән.

Территориаль органнарның эш графигы: дүшәмбе – җомга: 08.00 дән 17.00 гә кадәр, төшке аш вакыты 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре.

Социаль хезмәт күрсәтүче оешмаларның эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән тыш, көн саен, социаль хезмәт күрсәтүче оешмаларның эчке тәртип кагыйдәләре белән билгеләнә торган эш сәгатьләрендә.

1.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) территориаль органнарда, социаль хезмәт күрсәтүче оешмаларда урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматтан торган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендлары аша.

Мәгълүмат стендларында бу Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3 – 2.5, 2.8, 2.10, 5.1 – 5.9 пунктларында күрсәтелгән мәгълүмат булырга тиеш;

2) “Интернет” челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында – http://mtsz.tatarstan.ru;

Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru);

Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru);

3) Министрлыкка, территориаль органнарга, социаль хезмәт күрсәтүче оешмаларга телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Министрлыкка, территориаль органнарга, социаль хезмәт күрсәтүче оешмаларга язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

Министрлыкның “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – “Интернет” челтәре) рәсми сайтының адресы: http://mtsz.tatarstan.ru.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә хәл ителә:

“Ветераннар турында” 12 гыйнвар, 1995 ел, № 5-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 3, 168 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Электрон имза турында” 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 63-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында” 28 декабрь, 2013 ел, № 442-ФЗ (алга таба – № 442-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2013, № 52 (1 өлеш), 7007 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт хезмәтләре яки муниципаль хезмәтләр реестрларына кертелергә тиешле һәм электрон рәвештә күрсәтелүче, дәүләт һәм муниципалитет учреждениеләре һәм дәүләт йөкләмәсе (заказы) яки муниципаль йөкләмә (заказ) урнаштырыла торган башка оешмалар тарафыннан күрсәтелүче хезмәтләр исемлеген раслау турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 25.04.2011 ел, № 729-р боерыгы белән расланган Дәүләт хезмәтләре яки муниципаль хезмәтләр реестрларына кертелергә тиешле һәм электрон рәвештә күрсәтелүче, дәүләт һәм муниципалитет учреждениеләре һәм дәүләт йөкләмәсе (заказы) яки муниципаль йөкләмә (заказ) урнаштырыла торган башка оешмалар тарафыннан күрсәтелүче хезмәтләр исемлеге (алга таба – № 729-р РФ Хөкүмәте боерыгы белән расланган Исемлек) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 18, 2679 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне көйләү турында” 18 декабрь, 2014 ел, № 126-ТРЗ

Татарстан Республикасы законы (алга таба – № 126-ТРЗ Татарстан Республикасы законы) ("Татарстан Дәүләт Советы хәбәрләре", 2014, № 12 (II өлеш), 1361 ст.);

"Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре" 15.08.2007, № 388 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Татарстан Республикасы Социаль яклау министрлыгының территориаль органы турында типовой нигезләмәне раслау хакында" 03.04.2006 ел, № 144 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2006, № 14, 0365 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында" 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 880 ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.5. Бу Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү (алга таба – социаль хезмәт күрсәтү) – гражданнарга социаль хезмәтләр күрсәтү буенча эшчәнлек;

социаль хезмәт – гражданинның яшәеш шартларын яхшырту һәм (яки) үзенең төп тормыш ихтыяҗларын мөстәкыйль тәэмин итү өчен мөмкинлекләрен арттыру максатында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә даими, вакыт-вакыт, бер тапкыр ярдәм күрсәтү, шул исәптән ашыгыч ярдәм күрсәтү буенча гамәл, яки гамәлләр;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) – дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать (27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль законның 2 статьясы 1 пункты). Гаризаның киңәш ителә торган формасы бу Регламентка 1 нче кушымтада китерелә;

социаль хезмәт күрсәтүче – оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә, социаль хезмәт күрсәтүне башкаручы юридик зат һәм (яки) шәхси эшмәкәр;

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның мәгълүмат керткәндә нигез булып торган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт хезмәтләре күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документларны кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләргә консультацияләр үткәрү "тәрәзә"се.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү атамасы | Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләрне күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтүе тәртибе турында мәгълүмат бирү. | № 729-р РФ Хөкүмәте карары белән расланган Исемлекнең 44 п. |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче орган (оешманың) атамасы | Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы яки шәһәр округларындагы Социаль яклау идарәләре (бүлекләре) йөзендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;<br>Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмалары | № 126-ТРЗ Татарстан Республикасы законының 5 ст. 2 өл. 6 п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып тора:<br>гариза бирүченең гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләрне күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтүе тәртибе турында мәгълүмат алуы (мәгълүмати хат);<br>гариза бирүчегә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләрне күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтүе тәртибе турында мәгълүмат бирүдән баш тарту. | |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең рөхсәт ителә торган максималь сроклары:<br>шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, 15 минуттан артмаска тиеш;<br>телефон аша шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, 10 минуттан артмаска тиеш; | |

| | | |
|---|---|---|
| | язмача мөрәҗәгать иткәндә, шул исәптән электрон почта аша – мөрәҗәгать теркәлгән моменттан 22 эш көненнән артык түгел. | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | Язмача, шул исәптән электрон документ рәвешендә мөрәҗәгать иткәндә – бу Регламентка 1 нче кушымтадагы форма нигезендә гариза. | |
| 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булып, мөрәҗәгать итүче тапшыруга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган документлар таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма | | |
| 2.7. Норматив-хокукый актларда күздә тотылган очракларда, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен аларның килештерүләре (дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла) таләп ителә торган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Килештерү таләп ителми. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр юк. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки аннан баш | Язмача, шул исәптән электрон документ рәвешендә мөрәҗәгать иткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләр булып | |

| | | |
|---|---|---|
| тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | торалар:<br>- гариза бирүче тарафыннан тиешенчә рәсмиләштерелмәгән гариза бирелү (тутырылмаган реквизитлар булу – үзенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), дәүләт хезмәте нәтиҗәсе җибәрелергә тиешле почта адресы язылмау, гариза текстын укып булмау, алдан килешенмәгән төзәтүләр кертү);<br>- әдәпсез яки мыскыллау сүзләре, вазыйфаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янау булу;<br>- гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләрне күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтүе тәртибе турында мәгълүмат бирүне сорау булып тормаучы мөрәҗәгать.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр билгеләнмәгән. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә. | № 210-ФЗ Федераль законның 8 ст.;<br>№ 126-ТРЗ Татарстан Республикасы законының 5 ст. 2 өл. 6 п. |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләргә түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, мондый түләү | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | № 442-ФЗ Федераль законның 9 ст. 2 п. |

| | | |
|---|---|---|
| күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны кертеп | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүченең кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүенең максималь срогы 15 минуттан артырга тиеш түгел.<br>Дәүләт хезмәте алучыларның аерым категорияләре өчен кабул итүне көтү чираты билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатен теркәү срогы, шул исәптән электрон рәвештә | Гариза кергән көнне. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урынына, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат урнаштыруга карата таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган биналарда башкарыла.<br>Гариза кабул итү өчен җаваплы һәр белгечнең эш урыны кирәкле мәгълүмат базаларына, "Интернет" челтәренә чыгу мөмкинлеге, бастыру җайланмасы (принтер) һәм күчермә ясау җайланмасы булган персональ компьютер белән җиһазландырылган булырга тиеш. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең мөмкинлек һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып торалар:<br>гаризаны кабул итү һәм карап тикшерү сроклары үтәлү;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу срогы үтәлү; | |

| | | |
|---|---|---|
| гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән аралашулары саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәктә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып | дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан Регламент бозылу очракларының (нигезле шикаятьләрнең) булу-булмавы;<br>гариза бирүченең территориаль органнар, социаль хезмәт күрсәтүче оешмалар белгечләре белән аралашуы саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны биргәндә, турыдан-туры – бердән артык түгел (консультацияәрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны почта аша, шул исәптән № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәргәндә, – таләп ителми (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы белгечләр белән аралашуы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (алга таба – КФҮ), КФҮнең ерактагы эш урыннары аша күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турындагы мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан http://mtsz.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан алынырга мөмкин. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп, гариза бирүченең электрон имзасы белән имзаланган гариза дәүләт хезмәте күрсәтүче территориаль органга, социаль хезмәт күрсәтүче оешмага Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша (http://uslugi.tatar.ru) җибәрелергә мөмкин. | № 63-ФЗ Федераль законның 2 ст. 11 п.;<br>№ 210-ФЗ Федераль законның 21.1 ст. |

**3. Административ процедуралар (гамәлләр) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрнең ерактагы эш урыннарында үтәү үзенчәлекләре**

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы.

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) гаризаны кабул итү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен карап тикшерү;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак, мәгълүмати хат әзерләү;

4) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы бу Регламентка 2 нче кушымтада бирелгән.

3.2. Гариза бирүче территориаль органга яки социаль хезмәт күрсәтүче оешмага телдән (шул исәптән телефон аша) мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүчегә консультация бирү, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле гаризаның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны рәсмиләштерү өлешендә дә территориаль орган яки социаль хезмәт күрсәтүче оешма белгече тарафыннан башкарыла.

Бу пункт билгели торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне үтәлә. Административ процедураның дәвамлылыгы, шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, консультация бирү башланган моменттан 15 минуттан һәм телефоннан сөйләшә башлаган моменттан 10 минуттан артмаска тиеш.

Административ процедура нәтиҗәсе: тапшырылган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультация бирү, гариза бирүчегә күрсәтелгән ярдәм, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен карап тикшерү

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән яки телефон аша территориаль органга яки социаль хезмәт күрсәтүче оешмага мөрәҗәгать итә.

Гариза бирүче шәхсән телдән, шул исәптән телефон аша, территориаль органга яки социаль хезмәт күрсәтүче оешмага дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткәндә, территориаль орган яки социаль хезмәт күрсәтүче оешма белгече түбәндәгеләрне башкара:

гариза бирүченең шәхесен аныклый (фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы булса));

телдән мөрәҗәгатьне гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә

социаль хезмәтләрне күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтүе тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны теркәү журналында (алга таба – гаризаларны теркәү журналы) терки;

социаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында телдән мәгълүмат бирә.

Бу пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне үтәлә. Административ процедураның дәвамлылыгы, шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, консультация бирү башланган моменттан 15 минуттан һәм телефоннан сөйләшә башлаган моменттан 10 минуттан артмаска тиеш.

Процедуралар нәтиҗәсе: гаризаларны теркәү журналында теркәү язуы, дәүләт хезмәте күрсәтү.

3.3.2. Гариза бирүче территориаль органга яки социаль хезмәт күрсәтүче оешмага гариза тапшыра.

Гариза, җибәрелү фактын һәм көнен раслау мөмкинлеге булган ысул белән, почта аша җибәрелергә мөмкин.

Электрон документ рәвешендә җибәрелгән гариза № 63-ФЗ Федераль законга һәм № 210-ФЗ Федераль законга туры китереп имзалана һәм территориаль органга яки социаль хезмәт күрсәтүче оешмага электрон җайланмалардан файдаланып һәм (яки) Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшырыла.

Почта аша, яки Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон документ рәвешендә тапшырылган гариза бу Регламентның 3.3 пункты нигезендә карап тикшерелә.

Территориаль орган яки социаль хезмәт күрсәтүче оешма белгече гаризаны гаризалар теркәү журналында терки һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен бу Регламентның 2.9 пунктында күздә тотылган нигезләрнең булу-булмавын тикшерә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен бу Регламентның 2.9 пунктында күздә тотылган нигезләр булган очракта, территориаль орган яіи социаль хезмәт күрсәтүче оешма белгече, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булуны хәбәр итә.

Бу пунктча билгели торган процедуралар гариза алынган моменттан башлап алты эш көне эчендә үтәлә.

Административ процедуралар нәтиҗәсе булып тора: гаризаларны теркәү журналында теркәү язуы, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итү.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак, мәгълүмати хат әзерләү

3.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен бу Регламентның 2.9 пунктында күздә тотылган нигезләр булмаган очракта, территориаль орган яіи социаль хезмәт күрсәтүче оешма белгече:

мәгълүмати хат проектын рәсмиләштерә;

мәгълүмати хат проектын имза кую өчен территориаль орган

җитәкчесенә яки социаль хезмәт күрсәтүче оешма җитәкчесенә җибәрә.

Бу пунктча билгели торган процедуралар 3.3.2. пунктчасында күздә тотылган процедуралар тәмамланган моменттан башлап унөч эш көне эчендә үтәлә.

Административ процедуралар нәтиҗәсе булып, мәгълүмати хат проекты тора.

3.4.2. Территориаль орган җитәкчесе яки социаль хезмәт күрсәтүче оешма җитәкчесе, мәгълүмати хат проектын карап тикшергәннән соң, аны имзалый һәм территориаль орган яки социаль хезмәт күрсәтүче оешма белгеченә җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедура мәгълүмати хат проекты имза куюга җибәрелгән моменттан башлап ике эш көне эчендә үтәлә.

Административ процедура нәтиҗәсе булып, территориаль орган җитәкчесе яки социаль хезмәт күрсәтүче оешма җитәкчесе имзалаган мәгълүмати хат тора.

3.5. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру

Территориаль орган яки социаль хезмәт күрсәтүче оешма белгече, гаризада күрсәтелгән ысул белән, гариза бирүчегә мәгълүмати хатны җибәрә.

Бу пунктча билгели торган процедура 3.4.2 пунктчасында күздә тотылган процедура тәмамланган моменттан башлап бер эш көне эчендә үтәлә.

Административ процедура нәтиҗәсе булып, гариза бирүчегә җибәрелгән мәгълүмати хат тора.

3.6. Дәүләт хезмәте КФҮ, КФҮнең ерактагы эш урыны аша күрсәтелми.

3.7. Техник хаталарны төзәтү

Мәгълүмати хатны үзгәртеп рәсмиләштерү элегрәк бирелгән (җибәрелгән) мәгълүмати хатта җибәрелгән техник хаталарны (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хаталар, яисә башка хаталар) бетерүгә бәйле рәвештә башкарыла.

Мәгълүмати хатны үзгәртеп рәсмиләштерү гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән техник хаталы мәгълүмати хат кушып теркәлгән гариза (гаризаның киңәш ителә торган формасы бу Регламентка 3 нче кушымтада китерелгән) нигезендә башкарыла.

3.7.1. Территориаль орган яки социаль хезмәт күрсәтүче оешма белгече:

техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә һәм техник хатаны төзәтү турындагы гаризаларны теркәү журналында (4 нче кушымта) терки;

мәгълүмати хат проектын үзгәртеп рәсмиләштерә;

үзгәртеп рәсмиләштерелгән мәгълүмати хат проектын территориаль орган җитәкчесенә яки социаль хезмәт күрсәтүче оешма җитәкчесенә имза куюга җибәрә.

Бу пунктча билгели торган процедуралар гариза теркәлгән моменттан башлап биш эш көне эчендә үтәлә.

Административ процедуралар нәтиҗәсе булып, техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, үзгәртеп рәсмиләштерелгән, территориаль орган җитәкчесенә яки социаль хезмәт күрсәтүче оешма җитәкчесенә имза куюга җибәрелгән мәгълүмати хат проекты тора.

3.7.2. Территориаль орган җитәкчесе яки социаль хезмәт күрсәтүче оешма җитәкчесе үзгәртеп рәсмиләштерелгән мәгълүмати хатны имзалый һәм аны территориаль орган яки социаль хезмәт күрсәтүче оешма белгеченә җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедура мәгълүмати хат проекты имза куюга җибәрелгән моменттан башлап ике эш көне эчендә үтәлә.

Административ процедура нәтиҗәсе булып, имзаланган үзгәртеп рәсмиләштерелгән мәгълүмати хат тора.

3.7.3. Территориаль орган яки социаль хезмәт күрсәтүче оешма белгече үзгәртеп рәсмиләштерелгән мәгълүмати хатны, гаризада күрсәтелгән ысул белән, гариза бирүчегә җибәрә.

Бу пунктча билгели торган процедура 3.7.2. пунктчасында күздә тотылган процедура тәмамланган моменттан башлап бер эш көне эчендә үтәлә.

Административ процедура нәтиҗәсе булып, гариза бирүчегә җибәрелгән үзгәртеп рәсмиләштерелгән мәгълүмати хат тора.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итү тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген үтәүгә агымдагы контрольлек территориаль орган җитәкчесе һәм социаль хезмәт күрсәтүче оешма җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

4.2. Территориаль орган, социаль хезмәт күрсәтүче оешма белгечләре (вазыйфаи затлары) тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгына һәм сыйфатына контрольлек Министрлыкның социаль хезмәт күрсәтү сыйфатын идарә бүлеге тарафыннан башкарыла.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфатына контрольлек үз эченә тикшерүләр үткәрүне, дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы белгечләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләрне карап тикшерүне, карарлар кабул итү һәм җаваплар әзерләүне ала.

Административ процедураларның үтәлүенә контрольлек формалары булып түбәндәге тикшерүләр үткәрү тора:

делопроизводство алып баруны, шул исәптән документларны кабул итү сроклары һәм тәртибе үтәлүне;

гаризаны карап тикшерү нәтиҗәләренең законнар (бу Регламент) таләпләренә туры килүен;

дәүләт хезмәте күрсәткәндә нәтиҗәләрне бирү сроклары һәм тәртибе үтәлүне.

Тикшерүләр уздыруның ешлыгы планлы характерда (эш планнары

нигезендә башкарыла) һәм планнан тыш характерда (гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) була.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гражданнар, аларның берләшмәләре, оешмалары тарафыннан контрольлек итү территориаль орган, социаль хезмәт күрсәтүче оешма эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге ярдәмендә башкарыла.

4.5. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә дәүләт хезмәте алганда гражданнарның хокуклары бозылу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, яки дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Гариза бирүчеләр судка кадәр тәртиптә түбәндәгеләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерергә хокуклы:

территориаль орган белгечләренең – территориаль орган җитәкчесенә;

социаль хезмәт күрсәтүче оешма белгечләренең – социаль хезмәт күрсәтүче оешма җитәкчесенә.

Социаль хезмәт күрсәтүче оешма җитәкчесе кабул иткән карарларга шикаять территориаль орган җитәкчесенә бирелә, территориаль орган җитәкчесе кабул иткән карарларга – Министрлыкка шуның белән шөгыльләнүче министр урынбасары исеменә, шуның белән шөгыльләнүче министр урынбасары кабул иткән карарларга – министрга, министр кабул иткән карарларга карата шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелергә мөмкин.

5.2. Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризасын теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп иткәндә;

4) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең аларга туры китереп кабул

ителгән башка норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаса;

6) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

5.3. Шикаять язмача кәгазьдә яки электрон рәвештә бирелә.

Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://www.mtsz.tatar.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru) файдаланып җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаятьне карап тикшерү срогы – аны теркәгән көннән башлап унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче территориаль орган яки социаль хезмәт күрсәтүче оешма белгеченең гариза бирүчедән гаризаны кабул итеп алудан яисә җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына карата шикаять белдерелү очрагында яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерелү очрагында – аны теркәгән көннән башлап биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче территориаль органның яки социаль хезмәт күрсәтүче оешманың атамасы, территориаль органның яки социаль хезмәт күрсәтүче оешманың дәүләт хезмәте күрсәтүче белгече (вазыйфаи заты ) яки дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) гражданинның – физик затның – фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүматлар, яки гариза бирүченең – юридик затның – атамасы, урнашкан урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), гражданинга җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәвен нигезләүче дәлилләр.

5.6. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре кушып бирелергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа кушып бирелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.7. Шикаятькә аны тапшырган гариза бирүче имза куя.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча бу Регламентның 5.1 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи затлар түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акчаны гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Бу Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гражданинга язмача һәм гариза бирүченең теләге буенча, электрон рәвештә, шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү буенча вәкаләт бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны, кичекмәстән, прокуратура органнарына җибәрә.

Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләрне күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтүе тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителә торган форма

______________________________________________________________________,
*(дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче орган (оешма) атамасы)*

түбәндәге адрес буенча теркәлгән:
______________________________________________________________________
*(индексын, РФ субъектын, шәһәрне (авыл, бистә), урам, йорт һәм фатир номерын күрсәтергә кирәк)*

түбәндәге адрес буенча яшәүче:
______________________________________________________________________
*(индексын, РФ субъектын, шәһәрне (авыл, бистә), урам, йорт һәм фатир номерын күрсәтергә кирәк)*

______________________________________________________ нан (дән)
*(гражданинның Ф.И.О. тулысынча)*

Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләрне күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтүе тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында
ГАРИЗА

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
____________________________________________________________мәсьәләсе
буенча мәгълүмат бирүегезне үтенәм.

“Персональ мәгълүматлар турында” 27.07.2006 ел, № 152-ФЗ Федераль законга нигезләнеп, бу Гаризада күрсәтелгән шәхси мәгълүматларымны җыюга, эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган эшкәртүгә, саклауга һәм мәгълүмат алмашу системасындагы өченче затларга тапшыруга ризалыгымны бирәм.
Мәгълүматны, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) ________________________________ алырга риза
*(язмача, электрон почта белән).*

“__” ________ 20__ ел                                   Имза _____________

Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләрне күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтүе тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

**Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләрне күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтүе тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең блок-схемасы**

Гариза бирүче

↓

Территориаль органга яки социаль хезмәт күрсәтүче оешмага дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү

↓ ↓

| | |
|---|---|
| Телдән (шәхсән яки телефоннан) | Язмача, шул исәптән электрон документ рәвешендә |
| ↓ | ↓ |
| Дәүләт хезмәте күрсәтү | Гаризаны теркәү һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең булу-булмавын тикшерү. Баш тарту өчен нигезләр булганда – гариза бирүчегә алты эш көне эчендә хәбәр итү |
| ↓ | ↓ |
| Территориаль орган белгече яки социаль хезмәт күрсәтүче оешма белгече дәүләт хезмәте күрсәтү турында дәүләт хезмәте күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) теркәү журналында язып куя | Мәгълүмати хат проектын әзерләү һәм территориаль орган җитәкчесенә яки социаль хезмәт күрсәтүче оешма җитәкчесенә имза куюга җибәрү – унөч эш көне эчендә |
| | ↓ |
| | Мәгълүмати хат проектына кул кую һәм территориаль орган яки социаль хезмәт күрсәтүче оешма белгеченә җибәрү |
| | ↓ |

Гариза бирүчегә мәгълүмати хатны җибәрү – бер эш көне эчендә

Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләрне күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтүе тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

____________________________________________
____________________________________________
____________________________________________
*(дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче орган (оешма) атамасы)*

житәкчесенә
____________________________________________
______________________________ дан (нан)

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Мин,____________________________________________________________________,
*(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)*

түбәндәге адрес буенча яшим: _________________________________________________
____________________________________________________________________________
*(индексын күрсәтеп, гариза бирүченең почта адресы, телефоны, электрон адресы)*

____________________________________________________________________________
*(гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документ атамасы, аның сериясе, номеры, бирү көне,*

____________________________________________________________________________
*документны биргән орган атамасы)*

_______________ № _______________ мәгълүмати хатта

җибәрелгән техник хатаны __________________________________ төзәтүне үтенәм.
Дәүләт хезмәтен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында үзгәртелеп рәсмиләштерелгән карарны __________________________________ алырга риза.
*(язмача, электрон почта белән)*

“__” ________ 20__ ел _______________ ___________________________
*(гариза бирүче имзасы)* *(тулы имза)*

Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләрне күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтүе тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Техник хатаны төзәтү турындагы гаризаларны теркәү

ЖУРНАЛЫ

| Теркәү номеры (№) | Гариза бирү датасы | Үзгәртеп рәсмиләштерелгән мәгълүмати хатны бирү (җибәрү) датасы |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | |

Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләрне күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтүе тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмә)

Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләрне күрсәтүчеләрнең социаль хезмәтләрне күрсәтүе тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы органнар (оешмалар) һәм вазыйфаи затлар турында мәгълүматлар

1. Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтүче оешмалары

1.1. Картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернатлар

| Т-п № | Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтүче оешмасы атамасы | Телефон | Адрес | Эш графигы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | “Азнакай картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернаты” ГАУСО | (8-85592) 6-06-92 | 423304, Актүбә ш.т.б., Комаров ур., 1й. E-mail: Galina.Shaydullina@tatar.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2 | “Актаныш картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернаты” ГАУСО | (8-85552) 5-12-46, 5-12-48 | 423730, Поисево ав., М. Шакиров ур., 33 й. E-mail: Razuda.Gapsalamova@tatar.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |
| 3 | “Алексеевск картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернаты” ГАУСО | (8-84341) 4-02-09, 4-02-33, 4-02-45 | 422914, Большие Полянки ав., Озерная ур., 50 й. E-mail: Zayceva.Elena@tatar.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |
| 4 | “Әлки картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернаты” ГАУСО | (8-84346) 7-41-95, 7-42-44 | 422885, Юхмачы ав., Школьная ур., 13 й. E-mail: Gulchechek.Mubaraksh@tatar.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |
| 5 | “Арча картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернаты” ГАУСО | (8-84366) 3-15-17, 3-15-18 | 422000, Арча ш., Левитан ур., 6 й. E-mail: Arsk.Dipi@tatar.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |
| 6 | “Баулы картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернаты” ГАУСО | (8-85569) 3-65-54, 3-65-56 | 423924, Кырым-Сарай ав., Совет ур., 59г й. E-mail: internat.dom@tatar.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 16.15 кә кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 7 | “Буа картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернаты” ГАУСО | (8-84374) 3-15-54, 3-33-79, 3-45-49 | 422430, Буа ш., Ефремов ур., 141 й. E-mail: buadomp@mail.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |
| 8 | “Югары Ослан картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернаты” ГАУСО | (8-84379) 2-22-05, 2-23-83 | 422570, Югары Ослан ав., Печище тракты, 3 й. E-mail: Serebryakova.Eleonor@tatar.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 16.00 гә кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |
| 9 | “Җәлил картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернаты” ГАУСО (Сарман районы) | (8-85573) 6-36-34, 6-36-35 | 423368, Җәлил ш.т.б., Лесная ур., 2 й. E-mail: internatdjalil@rambler.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 7.30 дан 16.30 га кадәр, төшке ял: 11.00 дән 12.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |
| 10 | “Алабуга картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернаты” ГАУСО | (8-85557) 7-50-91, 7-50-84 | 423600, Алабуга ш., Нефтьчеләр пр., 82 й. E-mail: Elab.Domi@tatar.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |
| 11 | “Кайбыч картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернаты” ГАУСО | (8-84370) 3-42-72 | 422321, Федоровское ав., Пролетарская ур., 54 й. E-mail: Kai.Dipi@tatar.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 12 | “Корноухово картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернаты” ГАУСО (Балык Бистәсе районы) | (8-84361) 2-71-54, 2-71-09 | 422644, Корноухово ав., Совхоз ур., 5 й. E-mail: Ramziya.Satdinova @ tatar.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 16.30 га кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |
| 13 | “Лениногорск картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернаты” ГАУСО | (8-85595) 6-07-03, 6-07-05 | 423250, Лениногорск ш., Октябрьская ур., 184 й. E-mail: Gayaz.Nazmuddinov @tatar.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |
| 14 | “Лесхоз картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернаты” ГАУСО (Саба районы) | (8-84362) 4-43-36, 4-43-34 | 422062, Лесхоз бис., Лагерная ур., 6 й. E-mail: I.Nurgaleev@tatar.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 7.00 дән 16.00 гә кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |
| 15 | “Мамадыш картлар һәм инвалидлар өчен махсус йорт-интернаты” ГАУСО | (8-85563) 2-52-01, 2-52-99 | 422145, Шәдче ав., Молодежная ур., 13 й. E-mail: tafrius123@mail.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 16.15 кә кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |
| 16 | “Минзәлә картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернаты” ГАУСО | (8-85555) 3-47-21, 3-46-65 | 423700, Минзәлә ш., Изыскателей ур., 1/27 й. E-mail: Gulnaz.Usmanova@t atar.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 17 | “Мөслим картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернаты” ГАУСО | (8-85556) 2-54-70, 2-34-37 | 423970, Мөслим ав., Набережная ур., 22 й. E-mail: Gulnar.Shakiryanova@tatar.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 16.30 га кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |
| 18 | “Чаллы картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернаты” ГАУСО | (8-8552) 70-46-89, 70-44-85 | РТ, 423800 ТР, Чаллы ш., Казан пр., 10 й. E-mail: Landysh.Martynova@tatar.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |
| 19 | “Яңа Чишмә картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернаты” ГАУСО | (8-84348) 2-27-03, 2-25-90 | 423190, Яңа Чишмә ав., Совет ур., 69 й. E-mail: Natalya.Shilova@tatar.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 16.15 кә кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |
| 20 | “Нурлат картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернаты” ГАУСО | (8-84345) 2-46-38, 2-46-26, 2-46-25 | 423040, Нурлат ш., Нурлат ур., 1 й. E-mail: Liliya.Fassahova@tatar.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |
| 21 | “Спас картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернаты” ГАУСО | (8-84347) 3-02-67, 3-05-33 | 422840, Болгар ш., Хирург Шеронов ур., 6 й. E-mail: Irina.Ivanovskaya@tatar.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 22 | “Тәтеш картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернаты” ГАУСО | (8-84373) 5-66-30, 2-62-32 | 422374, с.Зур Шәмәк ав., Пролетарская ур., 32 й. E-mail: Lyudmila.Samarkina@tatar.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 16.00 гә кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |
| 23 | “Тукай картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернаты” ГАУСО | (8-8552) 79-71-07, 79-70-66 | 423874, Тукай районы, Теләнче Тамак ав., Больница ур., 20 й. E-mail: TukaiDipi@yandex.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 16.15 кә кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |
| 24 | “Федоровский картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернаты” ГАУСО (Аксубай районы) | (884344) 4-20-18, 4-20-04 | 423070, Федоровский ав. E-mail: sdipi.aks@tatar.ru | Эш графигы: Дүшәмбе: 8.00 дән 17.00 гә кадәр, сишәмбе – җомга: 8.00 дән 16.00 гә кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |
| 25 | “Чирмешән картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернаты” ГАУСО | (8-84396) 2-54-05, 2-26-72 | 423100, Чирмешән ав., Техническая ур., ?? й. E-mail: Gulyuza.Hasanshina@tatar.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 26 | “Юлдаш” Чистай картлар һәм инвалидлар өчен йорт-интернаты” ГАУСО | (8-84342) 4-85-67, 4-86-12 | 422982, Чистай ш., Полющенков ур., 15 й. E-mail: Dom.Internat@tatar.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |

1.2. Психоневрология интернатлары

| Т-п № | Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтүче оешмасы атамасы | Телефон | Адрес | Эш графигы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | “Алабуга психоневрология интернаты” ГАУСО | (8-85557) 7-08-04, 7-83-18 | 423605, Алабуга ш., М. Горький ур., 115 й. E-mail: Kppni.nk@tatar.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |
| 2 | “Зеленодольск психоневрология интернаты” ГАУСО | (8-84371) 3-13-35, 3-35-08, 3-71-39 | 422540, Зеленодольск ш., Гайдар ур., 15 й. E-mail: Dispnrv.zel@tatar.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 15.30 га кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |
| 3 | “Казан психоневрология интернаты” ГАУСО | (843) 234-15-42, 234-62-33, 234-62-43 | 420075, Казан ш., Прибольничная ур., 1 й. E-mail: psinter.kzn@tatar.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 16.00 гә кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | көннәре |
| 4 | “Яңа Чуриле психоневрология интернаты” ГАУСО (Арча районы) | (8-84366) 5-22-43, 5-22-42, 5-21-06 | 422026, Яңа Чуриле ав., Сергин ур., 34 й. E-mail: Zulfiya.Zakiullina@tatar.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |
| 5 | “Чистай психоневрология интернаты” ГАУСО | (8-84342) 5-06-15, 5-45-58 | 422980, Психинтернат бис. E-mail: psih-internat@mail.ru | Эш графигы: Дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр, төшке ял: 12.00 дән 13.00 гә кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре |
